**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(278) -2-57-77
факс: 8-(278) -2-50-62

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(278) -2-57-77
факс: 8-(278) -2-50-62

2020 елның 30 гыйнварендәге 2 номерлы

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр исәпкә алып), «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә, **карар бирәм:**

1. 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә, 1, 2 нче кушымталар нигезендә, җирлекләр киселешендә, 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында -http:/laishevo.tatarstan.ru. адресы буенча бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Р. Нургалиев**

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 2 номерлы карарына
1 кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе ( сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3678,39 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 786,47 |
| 4. Кабер казу һәм күмү | 1660,00 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 2 номерлы карарына
2 кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе ( сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 178,39 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3500,00 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 786,47 |
| 5. Кабер казу һәм күмү | 1660,00 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |